**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**О внесении изменений в Положение о порядке формирования, подготовки и использования резерва управленческих кадров Республики Татарстан**

В целях совершенствования деятельности по формированию резерва управленческих кадров Республики Татарстан **постановляю**:

1. Внести в Положение о порядке формирования, подготовки и использования резерва управленческих кадров Республики Татарстан, утвержденное Указом Президента Республики Татарстан от 6 октября 2014 года № УП-968 «Об утверждении Положения о порядке формирования, подготовки и использования резерва управленческих кадров Республики Татарстан», следующие изменения:

а) в пункте 6 цифры «50» заменить цифрами «60»;

б) в пункте 8 слова «в возрасте от 27 до 55 лет» заменить словами «в возрасте до 55 лет»;

в) пункт 11 изложить в следующей редакции:

«11. Кандидаты в резерв управленческих кадров Республики Татарстан выдвигаются Президентом Республики Татарстан, Государственным Советником Республики Татарстан, Председателем Государственного Совета Республики Татарстан, Премьер-министром Республики Татарстан, заместителями Премьер-министра Республики Татарстан, Уполномоченным по правам человека в Республике Татарстан, Уполномоченным по правам ребенка в Республике Татарстан, Уполномоченным при Президенте Республики Татарстан по защите прав предпринимателей, руководителями государственных органов Республики Татарстан, председателем Совета муниципальных образований Республики Татарстан, главами муниципальных районов и городских округов Республики Татарстан, президентом Ассоциации предприятий и промышленников Республики Татарстан (региональное объединение работодателей), председателем Общественной палаты Республики Татарстан.

Граждане, желающие принять участие в конкурсном отборе в резерв управленческих кадров Республики Татарстан, направляют соответствующую заявку на имя лица, указанного в абзаце первом настоящего пункта.

Лицо, указанное в абзаце первом настоящего пункта, в течение семи рабочих дней со дня поступления от кандидата заявки проводит оценку его соответствия требованиям, установленным пунктом 8 настоящего Положения, и принимает решение о выдвижении либо об отказе в выдвижении кандидата на конкурсный отбор. О принятом решении кандидат уведомляется в письменной форме в течение пяти рабочих дней со дня принятия соответствующего решения.»;

г) пункт 25 изложить в следующей редакции:

«25. Подготовка лиц, состоящих в резерве управленческих кадров Республики Татарстан, осуществляется с учетом направления государственного и муниципального управления, предусмотренного пунктом 5 настоящего Положения, и включает в себя:

самоподготовку;

повышение квалификации, профессиональную переподготовку и стажировку;

подготовку и реализацию проекта, направленного на социально-экономическое развитие Республики Татарстан.

Под стажировкой в настоящем Положении понимается изучение лицами, включенными в резерв управленческих кадров Республики Татарстан, передового опыта в сфере государственного, муниципального и корпоративного управления, в том числе зарубежного, а также закрепление теоретических знаний, полученных ими при освоении программ повышения квалификации или профессиональной переподготовки, и приобретение практических навыков и умений для их эффективного использования.

За лицами, состоящими в резерве управленческих кадров Республики Татарстан, в целях оказания им содействия в профессиональном развитии и проработке проектов, направленных на социально-экономическое развитие Республики Татарстан, закрепляются наставники из числа лиц, указанных в абзаце первом пункта 11 настоящего Положения.»;

д) в пункте 31 абзац девятый признать утратившим силу;

е) дополнить разделом V следующего содержания:

«V. Оценка эффективности работы с резервом управленческих кадров Республики Татарстан

32. Анализ работы с резервом управленческих кадров Республики Татарстан и его использования ежегодно проводится Департаментом.

33. Эффективность работы с резервом управленческих кадров Республики Татарстан определяется по следующим показателям:

доля лиц, назначенных из резерва управленческих кадров Республики Татарстан, по отношению к общему количеству лиц, включенных в резерв управленческих кадров Республики Татарстан;

доля реализованных в Республике Татарстан проектов, направленных на социально-экономическое развитие Республики Татарстан и разработанных лицами, состоящими в резерве управленческих кадров

Республики Татарстан, по отношению к общему количеству указанных проектов;

доля лиц, принявших участие в образовательных программах и мероприятиях в период нахождения в резерве управленческих кадров Республики Татарстан.».

2. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Президент**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

Казань, Кремль
30 ноября 2019 года
№ УП-715

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы идарәче кадрлар резервын формалаштыру, әзерләү һәм файдалану тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы идарәче кадрлар резервын формалаштыру эшчәнлеген камилләштерү максатларында **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы идарәче кадрлар резервын формалаштыру, әзерләү һәм файдалану тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2014 елның 6 октябрендәге ПУ-968 номерлы Указы белән расланган Татарстан Республикасы идарәче кадрлар резервын формалаштыру, әзерләү һәм файдалану тәртибе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 6 пунктта «50» санын «60» санына алмаштырырга;

б) 8 пунктта «27 яшьтән алып 55 яшькә кадәр булган» сүзләрен «55 яше тулмаган» сүзләренә алмаштырырга;

в) 11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Татарстан Республикасы идарәче кадрлар резервына кандидатлар Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе, Татарстан Республикасы Премьер-министры, Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасарлары, Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил, Татарстан Республикасы дәүләт органнары җитәкчеләре, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советы рәисе, Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башлыклары, Татарстан Республикасы Предприятиеләре һәм сәнәгатьчеләре ассоциациясе президенты (эш бирүчеләрнең төбәк берләшмәсе), Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисе тарафыннан тәкъдим ителә.

Татарстан Республикасы идарәче кадрлар резервына конкурс нигезендә сайлап алуда катнашырга теләгән гражданнар әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән зат исеменә тиешле гариза җибәрә.

Әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән зат кандидаттан гариза алынган көннән җиде көн дәвамында аның әлеге Нигезләмәнең 8 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килү-килмәвенә бәя бирә һәм кандидатны конкурс нигезендә сайлап алуга тәкъдим итү яисә тәкъдим итмәү турында карар кабул итә. Кабул ителгән карар турында кандидатка язма рәвештә әлеге карар кабул ителгән көннән биш эш көне дәвамында хәбәр ителә.»;

г) 25 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«25. Татарстан Республикасы идарәче кадрлар резервында торучы затларны әзерләү әлеге Нигезләмәнең 5 пунктында каралган дәүләт һәм муниципаль идарә юлламасын исәпкә алып гамәлгә ашырыла һәм аңа түбәндәгеләр керә:

үзлегеннән әзерлек алу;

квалификация күтәрү, һөнәри яктан яңадан әзерлек алу һәм стажировка;

Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсешенә юнәлдерелгән проект әзерләү һәм гамәлгә ашыру.

Әлеге Нигезләмәдә стажировка дигәндә, Татарстан Республикасы идарәче кадрлар резервына кертелгән затлар тарафыннан дәүләт, муниципаль һәм корпоратив идарә өлкәсендә, шул исәптән чит илләрдәге алдынгы тәҗрибәне өйрәнү, шулай ук квалификация күтәрү һәм һөнәри яктан яңадан әзерлек алу программаларын үзләштергәндә алынган теоретик белемнәрен ныгыту һәм аларны нәтиҗәле файдалану өчен гамәли күнекмәләр алу күздә тотыла.

Татарстан Республикасының идарәче кадрлар резервында торучы затларга аларның һөнәри үсешенә һәм Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсешенә юнәлдерелгән проектларны өйрәнүгә ярдәм күрсәтү максатларында әлеге Нигезләмәнең 11 пунктындагы беренче абзацта күрсәтелгән затлар арасыннан остазлар беркетелә.»;

д) 31 пунктта тугызынчы абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

е) түбәндәге эчтәлекле V бүлек өстәргә:

«V. Татарстан Республикасының идарәче кадрлар резервы белән эшләүнең нәтиҗәлелеген бәяләү

32. Татарстан Республикасының идарәче кадрлар резервы белән эшләүгә һәм аннан файдалануга анализны ел саен Департамент үткәрә.

33. Татарстан Республикасы идарәче кадрлар резервы белән эшләү нәтиҗәлелеге түбәндәге күрсәткечләр буенча билгеләнә:

Татарстан Республикасы идарәче кадрлар резервына кертелгән затларның гомуми санына карата Татарстан Республикасы Идарәче кадрлар резервыннан вазыйфага билгеләнгән затлар өлеше;

Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсешенә юнәлтелгән һәм Татарстан Республикасының идарәче кадрлар резервында торучы затлар тарафыннан эшләнгән проектларның гомуми санына карата Татарстан Республикасында тормышка ашырылган проектларның өлеше;

Татарстан Республикасы идарәче кадрлар резервында торган вакытта белем бирү программаларында һәм чараларда катнашкан затлар өлеше.».

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2019 ел, 30 ноябрь
№ ПУ-715